ЛЕНИНОГОРСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД ЛЕНИНОГОРСК
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
ЛЕНИНОГОРСК
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30.09.2021 г.Лениногорск № 57

Лениногорск шәһәр Советының 2019 елның 23 октябрендәге 208 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында» 2021 елның 28 июнендәге 228-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Лениногорск шәһәр Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск шәһәр Советының 2019 елның 23 октябрендәге 208 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

**5 статьяның 10 пунктындагы 3 абзацын** «, бюджетның бердәм счетында калдыклар белән идарә итү операцияләреннән тыш» сүзләре белән тулыландырырга;

**29 статьяның 27 пунктын** түбәндәге эчтәлектәге җөмлә белән тулыландырырга: «Принципалның кредит (заем, облигациядән тыш) вазыйфаларны үтәвен тәэмин итүче муниципаль гарантия (облигациядән тыш, заем), кредит шартнамәсендә (заем шартнамәсендә) һәм (яисә) күрсәтелгән муниципаль гарантия бирү турында шартнамәдә күрсәтелгән кредит (заем) акчаларыннан максатчан файдалануны үз ягыннан тикшереп торуны гамәлгә ашыру вазифасы билгеләнгән очракта бирелә.»;

**32 статьяның 2 өлешен** түбәндәге эчтәлектәге 2.1 пункт белән тулыландырырга:

«2.1) Россия Федерациясенең милли үсеш максатларын һәм аларга ирешү буенча ачык хакимият органнары эшчәнлегенең юнәлешләрен билгели торган документларда ;».

**(2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә)**

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми интернет-сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Лениногорск шәһәре
муниципаль берәмлеге Башлыгы,
Лениногорск шәһәре мэры Р.Г.Хөсәенов